**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе турында нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 13 июнендәге ПУ-215 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 7 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы Указының 7 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 7 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 7 декабрендәге ПУ-1171 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан

Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 5 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 16 март
№ 165

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 16 » мартындагы
165 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе (алга таба – Идарә) – Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең мөстәкыйль структур бүлекчәсе.

Идарәнең кыскартылган атамасы – ТР РЭИ.

2. Идарә Татарстан Республикасы Рәисен матди-техник тәэмин итү һәм аңа социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясен, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы консультатив, киңәшмә һәм башка органнарны һәм алар тарафыннан уздырыла торган чараларны мәгълүмати, финанс, матди-техник тәэмин итү максатында төзелде.

3. Идарә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә төзелә һәм үзенең эшчәнлегендә турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә буйсына.

4. Идарә үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе боерыкларына һәм шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Идарә турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

II. Идарәнең төп бурычлары

6. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисен финанс белән, матди-техник, мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү һәм аңа социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы консультатив, киңәшмә һәм башка органнар эшчәнлеген финанс белән, мәгълүмати, матди-техник һәм оештыру-техник яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан яисә аның катнашында уздырылган һәм шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе үткәрә торган киңәшмәләрне, конференцияләрне, башка чараларны финанс белән, оештыру-техник һәм матди-техник яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең социаль-көнкүреш шартларын тәэмин итүне оештыру;

үз вәкаләтләре кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе сметасы нигезендә финанс чаралары белән эш итү.

## III. Идарәнең төп функцияләре

7. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Рәисе указларын һәм боерыкларын, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең, Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесенең боерыкларын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кул куйган яисә раслаган килешүләрне, киңәшмәләр беркетмәләрен, йөкләмәләр исемлеген һәм башка оештыру-боеру документларын теркәү, исәпкә алу, саклау һәм юллауны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Рәисе инициативасы белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына карауга тапшырыла торган Татарстан Республикасы законнары проектларын, Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары проектларын, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасын, килешүләр, чыгышлар, мөрәҗәгатьләр, сәламләүләр текстларын һәм Татарстан Республикасы Рәисе кул куя торган башка документларны Татарстан Республикасының дәүләт телләренә тәрҗемә итү;

Татарстан Республикасы Рәисе указларын һәм боерыкларын, Татарстан Республикасы Рәисе раслый торган беркетмәләр һәм йөкләмәләр исемлекләрен, Татарстан Республикасы Рәисе имзалаган килешүләрне һәм хатларны редакцияләү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе катнашында уздырыла торган чараларның тавыш язмаларын стенографияләү һәм шәрехләү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең эшләр номенклатурасы нигезендә агымдагы архив өчен материаллар формалаштыру һәм аларны даими саклауга Татарстан Республикасының дәүләт архив фондына тапшыруны оештыру;

мөһерләр һәм штамплар ясау өчен заказлар рәсмиләштерү, аларның исәбен алып бару;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең чыгымнар сметасын формалаштыру һәм үтәү, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә кергән акчаның нәтиҗәле файдаланылуын контрольдә тоту;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә оператив, бухгалтерлык һәм статистик исәп алып баруны гамәлгә ашыру, финанс эшчәнлеген анализлау;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә керә торган акчаны, товарларны, кыйммәтле әйберләрне һәм төп чараларны тулысынча исәпкә алуны тәэмин итү, шулай ук аларның хәрәкәте белән бәйле операцияләрне бухгалтерлык хисабында вакытында чагылдырып бару;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә товарларны, кыйммәтле әйберләрне, исәп-хисапларны һәм акчаны инвентарьлаштыруны вакытында һәм сыйфатлы итеп уздыруны тәэмин итү;

заманча программалаштыру чараларыннан файдаланып, бухгалтерлык исәбенең прогрессив формаларын һәм ысулларын кертү;

касса дисциплинасының һәм хисап бирелә торган суммаларны тотуның катгый үтәлүен контрольдә тоту;

хезмәт хакы хисаплау һәм түләү, барлык дәрәҗәдәге бюджетларга, бюджеттан тыш дәүләт фондларына законнар нигезендә түләүләрнең вакытында күчерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә штат финанс дисциплинасының үтәлүен катгый контрольдә тоту;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә бухгалтерлык балансын һәм чыгымнар сметасының үтәлүе хакында хисапны төзү һәм билгеләнгән тәртиптә аларны тиешле органнарга тапшыру;

Идарәгә буйсынган оешмаларда бухгалтерлык исәп-хисабының торышын тикшерү;

салым һәм финанс контроле дәүләт органнары һәм шулай ук банклар белән үзара хезмәттәшлек буенча эш оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең бухгалтерлык документларын саклауны тәэмин итү, аларны рәсмиләштерү һәм билгеләнгән тәртиптә архивка тапшыру;

Идарә карамагындагы мәсьәләләр кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының финанс мәсьәләләре буенча норматив-хокукый актларын эшләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы киңәшмә, консультатив һәм башка органнар эшчәнлегенә мәгълүмати ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә автоматлаштыру һәм цифрлаштыру системаларын эшләү һәм үстерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләрен документлар белән тәэмин итү өчен мәгълүмати-техник системаларга техник ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренә эчке мәгълүмат ресурсларына, тышкы тармак һәм территориаль мәгълүмат системаларына һәм челтәрләренә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә чыгу мөмкинлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе мәгълүмати ресурсларында мәгълүматны эшкәрткәндә һәм саклаганда аның саклануын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә хезмәткәрләрне компьютер технологияләренә һәм офис җиһазлары белән эшләргә өйрәтүне оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә кабель телевидениесе, радио, телефон элемтәсе һәм Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләре һәм җитәкчелеге катнашкан чараларда техник тавыш көчәйтү системаларын үстерү һәм аларга хезмәт күрсәтү;

Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясен, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе биналарын һәм алар тирәсендәге территорияләрне карап тәртиптә тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

Идарә карамагындагы оешмалар объектларын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау буенча эшләрне координацияләү һәм контрольдә тоту;

Татарстан Республикасында булган чит ил һәм башка делегацияләргә хезмәт күрсәтү буенча оештыру-техник чаралар уздыру;

Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе биналарына керүнең билгеләнгән сак режимын һәм тәртипне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә хезмәт шартларын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә мобилизация әзерлеген, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә эшләүче хәрби бурычлары булган запастагы хезмәткәрләрне исәпкә алу һәм аларга броньнәр бирүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының рәсми һәм белешмә материалларын, норматив һәм башка төрле актларын бастырып чыгаруны техник тәэмин итү;

төрле төрдәге полиграфия продукциясен әзерләү;

Идарә карамагындагы оешмаларда рәсми делегацияләрне кабул итүне тәэмин итү;

товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны башкару, товарлар китерүчеләрне (подрядчыларны, эш башкаручыларны) билгеләү, Идарәнең төп функцияләрен башкару өчен сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә контрактлар төзү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан аларда катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләр белән эш итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә вәкаләтле структур бүлекчә функцияләрен башкару.

Идарә Татарстан Республикасы Рәисе йөкләве буенча башка функцияләр башкара.

## IV. Идарәнең хокуклары

8. Үзенең бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Идарә түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, шулай ук аларның структур бүлекчәләренең мәгълүматлар базасыннан билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

мәгълүмат-белешмә һәм аналитик материалларны, шул исәптән электрон рәвештә, бастырып чыгарырга;

Идарә карамагындагы мәсьәләләр буенча эшне камилләштерүгә бәйле тәкъдимнәр эшләп Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә карап тикшерүгә кертергә.

9. Идарә үзенә йөкләнгән функцияләрне башкарганда юридик зат хокукларына ия, аның үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле, шул исәптән Татарстан Республикасының Дәүләт Гербы сурәте төшерелгән мөһерләре, штамплары, бланклары була, ул банкларда һәм башка кредит оешмаларында счетлар ача, шулай ук законнар нигезендә үзенең

карамагындагы оешмаларны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үти ала.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

10. Идарә үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

11. Идарәнең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын башкаручы хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар буенча үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

Идарәнең дәүләт граждан хезмәткәре булмаган хезмәткәрләре гомуми нигездә хезмәт турында законнар нигезендә җаваплы була.

## VII. Идарәнең эшчәнлеген оештыру

12. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

13. Идарә составына түбәндәгеләр керә:

бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге;

мәгълүмати-техник тәэминат бүлеге;

чараларга хезмәт күрсәтү һәм биналарны карап тоту бүлеге;

гомуми бүлек.

Идарәнең структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесенең тәкъдиме буенча раслана.

14. Идарә эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе (алга таба – Эшләр идарәчесе) җитәкчелек итә. Ул вазыйфага Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә билгеләнә һәм азат ителә.

Эшләр идарәчесе эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын Эшләр идарәчесе урынбасары яисә Идарәнең башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Эшләр идарәчесе:

үз компетенциясе кысаларында документларга кул куя һәм имза сала;

Идарә компетенциясенә кагылышлы оператив, оештыру-штат, кадрлар, финанс, җитештерү-хуҗалык һәм башка мәсьәләләрне хәл итү буенча

Идарәнең вазыйфаи затлары арасында вазыйфаларны бүлә һәм вәкаләтләр билгели;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Идарә компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча норматив-хокукый актлар проектлары эшләп, Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә;

Идарә компетенциясе чикләрендә чыгарылган боерыкларга, инструкцияләргә, кагыйдәләргә, нигезләмәләргә һәм башка төрле актларга кул куя һәм шулай ук аларның үтәлешен тикшерүне оештыра;

Идарә эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Рәисенә мәгълүмат бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтен биләүче Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү, бер урыннан икенче урынга күчерү, вазыйфадан азат итү хакында тәкъдим кертә;

законнар нигезендә аеруча зур уңышларга ирешкән Идарә хезмәткәрләрен һәм Идарә карамагындагы оешмалар хезмәткәрләрен бүләкләү турында тәкъдимнәр бирә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләмәгән Идарә хезмәткәрләрен бүләкләү һәм шулай ук аларга дисциплинар җәза бирү турындагы карарлар кабул итә;

Идарә карамагындагы оешмалар җитәкчелеге белән шартнамәләр (контрактлар) төзи һәм алар белән шартнамәне өзә, аларны вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә;

законда билгеләнгән тәртиптә Идарә карамагындагы оешмаларны үзгәртеп кору, Идарәгә буйсынган яңа оешмалар төзү кирәклеге хакында мәсьәләләрне хәл итә.

16. Эшләр идарәчесе урынбасары, Идарә бүлекләре мөдирләре Татарстан Республикасы Рәисе боерыклары нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

Идарәнең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын башкаручы хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыгы белән вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә. Идарәнең башка хезмәткәрләре Эшләр идарәчесе боерыгы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

17. Идарәнең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләре эшчәнлеге Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә җайга салына.

---